

Мордовиядә яшәгән картларыбыз хокvмәт һәм халык исеменнән хормәтләнә; Олылар айлыгында бәйрәмнәр дә vткәрелә. Шулай, vткән атнада Дубенка районы Ломат авылынын туган якны ойрәнv музеенда «Олкәннәр коне» чарасы узган.
Башта кунакларга бәйрәмне алып барган Мәзидә Якуп кызы Муракаева бу бәйрәмнен барлыкка килv тарихын сойләгән. Ул 1990 нчы елнын 14 нче октябрендә БМО 1 нче октябрьне Халыкара картлар коне дип игълан итәргә фәрман чыгара.      Россиядә бәйрәмне Кон иттереп кенә тvгел, ә ай буе олыларны хормәт итеп, торле-торле чаралар vткәрелә.
Бу бәйрәмгә жыелган Ломат авылынын хормәтле кешеләре, оештыручыга ярдәм йозеннән, Музейга экспонатлар (мәсәлән, Пикеев Рәшит Абдулхак улы борынгы шкаф-буфет, чигvле тарихи ястыктышны Рәзимә Таиб кызы Рахметуллова, Фаизә Аллям кызы Манякова сояктән тарак, һ.б.) белән бергә чәй остәленә милли тәмлушкалар, жиләк-жимеш тә алып килгәннәр. Бер-берсенә хормәт йозеннән ин матур, жылы, кvнелне жылытып жибәрә торган сvзләрен дә бvләк иткәннәр. Бәйрәмдә катнашучыларны Ломат авылы ветераннары советы рәисе Венера Салахетдиновна Алиева жылы һәм чын кvнелдән авылдашларын котлаган. Кунакларга кvнел тvреннән ургылып чыккан ихлас сvзләрен, теләкләрен хормәтле Альмира Бари кызы Раимова, Рәзимә Таиб кызы Рахметуллова, Фаилә апа Ишморатова әйттеләр.
Бик тә кызык vткән бу чара. Жан жылыткыч теләкләрдән сон, рәхәтләнеп конкурсларда һәм викториналарда катнашканнар. Чынаяк чәй артында кvнелгә ятышлы сойләшvләр дәвам иткән: яшьлекне искә тошергәннәр, традицион татар сыйларын, тәм-томнарын татып караганнар, бергәләп яраткан милли татар һәм башка халык жырларын башкарганнар. Авыллары музеенда экскурсия vткән. Гомумән, кондәлек мәшәкатьләрдән һәм проблемалардан ял иттеп, vзләренә кvнелле, онытылмаслык кич бvләк иткән оештыручылар. Кунаклар бу чараны озак жылы искә алырлар. Зур канәгатьлек белән мондый искиткеч бәйрәмне оештырганнары очен рәхмәтләрен дә белдергәннәр.
Олыласан олыны - олыларлар vзенне, ди халык бездә. Бу чараны оештыручы - авыл картлары белән бергә, Ломат музее житәкчесе Мәзидә Якуб кызы Муракаева. Музей житәкчесенен активлыгын, тырышлыгын Ботендонья татар конгрессы Рәхмәт хаты белән билгеләп vтә. Анда шундый сvзләр дә бар: “Милләтебез алдында олы хезмәтләрегезне искә алып, татар халкынын телен, мәдәниятын vстерvдә, гореф-гадәтләрен саклап калуда башкарган зур эшләрегез очен...” диелгән.